**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы**
**9 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- матур яңгырашлы, аһәңле, затлы сүз дигәнне аңлата;
- ул кемнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны данлау, киләчәк буыннар хәтеренә, халык күңеленә язып шул тарихта калдыру дигән сүз;
- бу жанрда иҗат ителгән әсәрләрнең күпчелеге үзәгендә алып-батыр яки пәһлеван образы тора.

**Җавап:** дастан

**2. Хаталбелән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) тарихи җыр, газәл, дастан, мөнәҗәт

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, җырлар, кыска җырлар

б) драма, комедия, трагедия, трагикомедия

**Җавап:** а) тарихи җыр, газәл, дастан, мөнәҗәт

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)





а) ә) б)





Җавап: 1) ә; 2) б; 3) а.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Габдулла Тукай «Пар ат»

Шәйхи Маннур «Муса»

Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Исмәгыйль а) «Сөйләнелмәгән хикәя»

2) Биктимер ә) «Галиябану»

3) Закир б) «Буранда»

4) Мостафа в) «Алмачуар»

**Җавап:** 1) ә; 2) а); 3) в; 4) б.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

Мин монда хокуклы. Тукталып,
Чакырсам, әгәр дә ым кагып,
Рухыма тиң булып, рухыма, –
Яныма басачак мең Алып.
... Моң салып нәселем үткән бит,
Кодрәтем биредә күптән бит:
Сак басам түмгәкләр өстенә,
Аягым корымас микән, дип.

Биредә күлләрем – күзгеләр,
Күзгеләр һәрберсе – изгеләр...
Кыл дога һәм күзәт үзеңне, –
Күлләр дә болгана, түзмиләр.

Күкрәктә тыпырдый кош, дулап,
Очыртсам – барасы юл ерак...
Ак кошым, пакь кошым, очма син,

Йөрик бер Ватанда, төш юрап.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьдә нинди ил турында сүз бара? (2 балл)**

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**в) Шигырьдәге теманы ачарга кайсы образлар ярдәм итә? Аларның мәгънәләрен аңлатып языгыз (4 балл)**_________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләгез (3 балл)** __________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Каеннар илендә

ә) Мөдәррис Әгъләмов

б) Шигырьдә туган ил, Ватан, Болгар иле турында сүз бара

в) Каеннар иле – туган ил, мең Алып – Ватанның батырлары, түмгәк – тарихтагы канлы вакыйгалар, күл-көзге – тарих, Ак кош – ирек.

г) Кеше туган илен, Ватанын яратырга, сакларга, аның тарихын белергә, аның белән горурланырга тиеш.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Аулак өй, кичен, җеп эрләү, бәйләү, чигү, сөлге, бирнә, кызлар, егетләр, гармун, күңелле, җыр-бию, уен-көлке, шат тавышлар.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы иреклe.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.